| ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570 | Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570 |

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерыгы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан районында яшәүчеләрнең уңайлы шартларга хокукларын, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру турындагы нигезләмә нигезендә, «АРМАДА» ҖЧҖ мөрәҗәгатен карап.

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Югары Ослан авылы, Автодорожная урамы, 4 йорт- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Югары Ослан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең инженерлык инфраструктурасы (И) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре зонасында «һава транспорты» 16:15:050108:168 кадастр номерлы, 5276 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручы - коллегиаль киңәшмә орган составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Әхмәтшин;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге А.Д. Сәгъдиева;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше башлыгы Н.В. Пичугина;

-Югары Ослан муниципаль районы  Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе  Т.М. Дәүләтшин.

4. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру чорын билгеләргә - 2025 елның 24 сентябреннән 2025 елның 13 октябренә кадәр.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы                Е.А. Варакин